ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
“ ИСКЕ РОМАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ”
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ
КАРАРЫ

"24 " сентябрь 2018 г. № 54/1

Чистай муниципаль районы
Иске Роман авыл җирлеге
территориясендә гражданнарга
үзара салым кертү һәм аның акчасын
файдалану мәсьәләсе буенча
җирле референдум билгеләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Жирле референдум турында” 2004 елның 25 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Чистай муниципаль районы “Иске Роман авыл җирлеге” Уставының 11 статьясы нигезендә, Иске Роман авыл җирлеге Советының “Референдум үткәрү инициативасы турында” 2018 елның 20 сентябрендәге 53/1 номерлы карары, Иске Роман авыл җирлеге Башкарма комитетының “Референдум үткәрү инициативасы турында” 2018 елның 20 сентябрендәге 8 номерлы карары белән, Иске Роман муниципаль берәмлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Чистай муниципаль районы Иске Роман авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны 2018 елның 18 ноябренә билгеләргә.
2. Җирле референдумга кертелә торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

“Сез Чистай муниципаль районы Иске Роман авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, көндезге бүлектә укучы талиблардан кала 2019 елда 300 сум күләмендә үзара салым салуны кертүгә һәм җыелган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә ризамы :

- Иске Роман авылы территориясендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау ( кардан чистарту,балчык китерү, гравий һәм щебень сатып алу);

- Иске Роман авылындагы зиратларны төзекләндерүгә (агачлар һәм куакларны кисүгә).

ӘЙЕ ЮК”.

3. Әлеге карарны Чистай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрдә, авыл җирлегенең халык күпләп җыела торган урыннарга, мәгълүмат стендлары һәм такталарына урнаштырырга.

Иске Роман авыл җирлеге
башлыгы Л.И.Садыкова